ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР
от 28.04.2020г

РЕШЕНИЕ
№46-06

2019 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе К.Р.Каюмованың 2019 елда Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы докладын тыңлап, фикер алышканнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Актаныш муниципаль районының 2019 елда бюджет үтәлеше турындагы хисапны, керемнәр буенча 1000 159,2 мең сум, төгәлләштерелгән план буенча - 960 672,7 мең сум, чыгымнар буенча 1 035 490,8 мең сум, төгәлләштерелгән план буенча -1 049 823,1 мең сум, дефицит белән -35 331,6 мең сум, төгәлләштерелгән план буенча -89 150,4 мең сум күләмендә расларга;
2. Актаныш муниципаль районының 2019 елга бюджет дефицитын финанслау чыганакларын 1 нче кушымта нигезендә расларга;
3. 2019 елда Актаныш муниципаль районы бюджетының фаразланучы керемнәре күләмен 2 нче кушымта нигезендә расларга;
4. 2019 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 3 нче кушымта нигезендә расларга;
5. Актаныш муниципаль районы бюджетының 2019 елга чыгымнар буенча ведомство структурасын 4 нче кушымта нигезендә расларга;
6. «2019 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары, төрләре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне» 5 нче кушымта нигезендә расларга.
7. 2019 елга Актаныш муниципаль районының муниципальара характердагы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлекләр бюджетларыннан субсидияләрне 6 нчы кушымта нигезендә расларга;
8. 2019 елга "Актаныш муниципаль районы бюджетыннан җирлекләргә дотацияләр күләмен" 7 нче кушымта нигезендә расларга;
9. 2019 елга "Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар" ны 8 нче кушымта нигезендә расларга.
10. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Актаныш таннары» газетасында урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе

Э.Н.Фаттахов